КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 апрель г.Казань № 280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче; 2015 ел, 7 август, 574 нче; 2016 ел, 1 сентябрь, 608 нче; 2017 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре җир асты байлыклары турында законнар нигезендә билгеле бер вакытка яки вакыты чикләнмичә файдалануга бирелә.

Җир асты байлыклары кишәрлекләре бер вакытка файдалануга түбәндәгеләр өчен бирелә:

геолгик өйрәнү – 5 елга кадәр вакытка;

файдалы казылмалар чыгару – җир асты байлыкларын рациональ файдалану һәм саклауны тәэмин итә торган файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртүнең техник-икътисадый нигезләүдән чыгып исәпләнә торган файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртү вакытына;

җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылганда җир асты байлыклары кишәрлекләреннән кыска вакытлы файдалану хокукы бирү нигезендә торган файдалы казылмалар чыгару – 1 елга кадәр вакытка;

җир асты суларын чыгару – 25 елга кадәр вакытка;

гомумтаралган файдалы казылмалардан торган һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы раслаган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән һәм «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 10.1 статьясындагы 6 пунктның сигезенче абзацы нигезендә файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару – уртак кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкару вакытына.

Файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләнмәгән вакытка бирелергә мөмкин.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җир асты байлыкларыннан бу файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозу булмаган шартларда, гомум таралган файдалы казылмалар чыганагын эзләүне һәм бәяләүне яки эшкәртүне тәмамлау яисә бетерү чараларын һәм җирләрне яңадан эшкәртүне башкару кирәк булган очракта җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану вакыты җир асты байлыкларыннан файдаланучы башлангычы белән озайтыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин